**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 01.09.2020** **№ 671**

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 27 апрелендәге 363 нче номерлы «Биектау муниципаль районы документларының мәҗбүри нөсхәсе турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

1994 елның 29 декабрендәге 78-ФЗ номерлы «Китапханә эше турында» Федераль закон, 1994 елның 29 декабрендәге 77-ФЗ номерлы «Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында» Федераль закон нигезендә, тулы китапханә-мәгълүмат фондын комплектлау, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль китапханәләрнең ресурс базасын булдыру һәм тулыландыру максатларында, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга таянып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 27 апрелендәге 363 нче номерлы «Биектау муниципаль районы документларының мәҗбүри нөсхәсе турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарына, 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2. Биектау муниципаль районында документларның мәҗбүри нөсхәсе составына керә торган документларны алу, саклау һәм иҗтимагый файдалану хокукын «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авылара китапханәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә бирергә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokaya-gora/tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин